ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 гыйнвар 2025ел № 559

Муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәтенә түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 145 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәтенә түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 30 гыйнварындагы
559 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәтенә түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә муниципаль унитар предприятиеләр (алга таба – предприятиеләр) җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәтенә түләү системасын җайга сала.

2. Әлеге нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе Хезмәт кодексындагы һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган актлардагы мәгънәдә кулланыла.

3. Предприятиеләр җитәкчеләренә хезмәткә түләү фондын формалаштырганда календарь елга исәпләп түләү өчен түбәндәге акчалар күздә тотыла:

1) вазыйфаи оклад - 12 түләү;

2) стимуллаштыру характерындагы түләүләр:

- эш нәтиҗәләре буенча премияләр - елына 12 вазыйфаи окладка кадәр;

- ел саен бирелә торган түләүле ял бирелгәндә бер тапкыр бирелә торган түләү - елына бер вазыйфаи оклад;

3) компенсация характерындагы түләүләр:

- нормалаштырылмаган эш көне шартларында эшли торган предприятие җитәкчеләренә ел саен бирелә торган өстәмә түләүле ял;

- хезмәт командировкасына бәйле чыгымнарны каплау.

4. Җитәкченең вазыйфаи окладын исәпләү өчен арттыру коэффициентын билгеләгәндә, вазыйфаи оклад билгеләнгән айның беренче числосына хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны исәпкә алына. Штат расписаниесен үзгәртү кварталга бер тапкырдан артык рөхсәт ителми.

5. Предприятиеләр җитәкчеләренең вазыйфаи окладлары предприятие җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе арасында төзелә торган хезмәт шартнамәләрендә теркәлә.

6. Предприятиеләр җитәкчеләренең хезмәтенә түләү вазыйфаи окладны, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне үз эченә ала.

2 бүлек. Предприятиеләр җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының вазыйфаи окладын формалаштыру тәртибе

7. Предприятие җитәкчесенең вазыйфаи оклады билгеләп куелган суммада билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$О_р = С_{1р} * Кк, \text{ монда:}$$

$О_р$ - предприятие җитәкчесенең вазыйфаи оклады;

$С_{1\ р}$ - Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы оешмалары буенча тармак килешүе нигезендә беренче разрядның айлык тариф ставкасы яисә предприятиенең төп эшчәнлек төрен гамәлгә ашыручы хезмәткәренең вазыйфаи оклад билгеләнә торган айның беренче числосына билгеләнгән уртача вазыйфаи оклады;

Кк - арттыру коэффициенты.

8. предприятие җитәкчеләренең вазыйфаи окладын исәпләү өчен түбәндәге арттыру коэффициентлары каралган:

1) торак-коммуналь хуҗалыгы оешмалары

Таблица

Предприятие җитәкчеләренең вазыйфаи окладын исәпләү өчен арттыру коэффициентлары

| Предприятие хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны | Беренче разрядлы айлык тариф ставкасы күләменә яисә төп эшчәнлек төре буенча хезмәткәрнең вазыйфаи окладына карата арттыру |
|---|---|
| 300 гә кадәр | 6 |
| 300 дән 400 гә кадәр | 7 |
| 400 дән 500 гә кадәр | 8 |
| 500 һәм аннан күбрәк | 9 |

9. Җитәкче урынбасарының, баш бухгалтерның вазыйфаи оклады предприятие җитәкчесенең вазыйфаи окладыннан 70 тән 90 процентка кадәр күләмдә билгеләнә. Җитәкче урынбасарының, баш бухгалтерның вазыйфаи окладының конкрет күләме хезмәт шартнамәсендә күрсәтелә.

Стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы башка түләүләр предприятиенең хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган локаль норматив актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

## 3 бүлек. Предприятиеләр җитәкчеләренә стимуллаштыру һәм компенсация түләүләре

10. Предприятиеләр җитәкчеләренә түбәндәге стимуллаштыру түләүләре билгеләнә:

1) эш нәтиҗәләре буенча премия. Премия предприятие җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре буенча һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиеләренең, устав капиталында муниципаль берәмлекнең 100% өлеше булган акционерлык җәмгыятьләренең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең эшчәнлек нәтиҗәләрен һәм бухгалтерлык хисаплылыгын карап тикшерү буенча баланс комиссиясе бекетмәсе нигезендә, квартал саен өч вазыйфаи окладка кадәр күләмдә билгеләнә. Предприятие җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары Башкарма комитет карары белән билгеләнә;

2) ел саен бирелә торган түләүле ял бирелгәндә түләү бер вазыйфаи оклад күләмендә билгеләнә.

11. Предприятиеләр җитәкчеләренә компенсация түләүләре:

1) Башкарма комитет боерыгы нигезендә предприятие җитәкчесе җибәрелгән хезмәт командировкасына бәйле чыгымнарны кайтару.

Предприятие җитәкчесе хезмәт командировкасына җибәрелгән очракта, юл йөрү, торак урынны наемга алу чыгымнары, даими яшәү урыныннан читтә яшәүгә бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек чыгымнар) кайтарыла;

2) нормалаштырылмаган эш көненә бәйле рәвештә ел саен бирелә торган өстәмә түләүле ял, төзелгән хезмәт шартнамәсе шартлары нигезендә, ел саен кимендә өч календарь көн дәвамында бирелә.

Предприятие җитәкчесенә ел саен бирелә торган өстәмә түләүле ял предприятие җитәкчесенең гаризасына нигезләнеп чыгарылган Башкарма комитет боерыгы нигезендә бирелә.

12. Предприятиенең коллектив шартнамәсе һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган локаль норматив актлары белән билгеләнә торган стимуллаштыру түләүләре предприятие җитәкчесенә кагылмый.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева